| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**Исполнительный комитет**<br>**поселка городского типа Уруссу**<br>**Ютазинского муниципального района** | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**Ютазы муниципаль районы**<br>**Урыссу шәһәр тибындагы поселогы**<br>**Башкарма комитеты** |
|---|---|
| 423950, п.г.т. Уруссу<br>ул. Пушкина, 38<br>тел. 2-88-02<br>2-92-40 | 423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы<br>Пушкин урамы, 38<br>тел. 2-88-02<br>2-92-40 |


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 31** **« 15 » июнь 2015 ел**

Ютазы муниципаль районының шәһәр тибындагы
Урыссу поселогы Башкарма комитетының “Алкогольле
продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер
оешмалар һәм объектлар тирәсендәге территорияләрне
билгеләү турында" 15.03.2013 ел, № 12 карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 декабрендәге 171-ФЗ номерлы һәм «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 18 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән гражданнарның массакүләм туплану урыннарын һәм югары куркыныч чыганакларын, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән һәм аерым территорияләр чикләрен билгеләү турында» карары, «Татарстан Республикасында халык арасында алкоголь продукциясен, сыра, тәмәке тартуны киметү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча өстәмә чаралар турында» 2010 елның 29 октябрендәге 867 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 24 сентябрендәге 788 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә,

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу тибындагы поселогы башкарма комитетының 15.03.2013 ел № 12 карарындагы 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Тирә-юнь территорияләренең ераклыклары тротуарларга, җәяүлеләр юлларына һәм җәяүлеләр кичүе буенча гражданнарның күпләп җыелу урыннарына һәм югары дәрәҗәдә хәвеф чыганакларының урнашу урыннарына караган объект чикләреннән алкогольле продукцияне ваклап сатучы сәүдә (җәмәгать тукlануы) предприятиесенә кергәнчегә кадәр үлчәнә. Ераклыкларны үлчәү җәяүленең иң кыска хәрәкәт маршруты буенча башкарыла:

- мәдәният оешмаларыннан, культура, физкультура-сәламәтләндерү, спорт учреждениеләреннән, күпләп һәм ваклап сату базарларыннан, вокзаллардан, балалар, мәгариф һәм медицина оешмалары биналарыннан һәм корылмаларыннан, җәмәгать транспорты тукталышларыннан, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләреннән, якын-тирә территорияләрендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган куркыныч җитештерү объектларыннан ераклык 20 метрдан да ким булмаска тиеш."

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны әлеге карар кабул ителгән вакыттан алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең территориаль органы игътибарына җиткерергә.

Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Ф. Вәдигуллин

Исмәгыйлева Т.Г.
2-92-40